| КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ<br>КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ<br>МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН<br>САКЛАУ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.03.2022 г.Казань № 44-П

Татарстан Ррспубликасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында урнашкан «Урта Куланга җирлеге» археологик мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү һәм территориясе чикләрен раслау турында» 2021 елның 17 февралендәге 33-П номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы «Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре» карары нигезендә боерам:

1. Әлеге боерыкка 1 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында урнашкан «Урта Куланга җирлеге» археологик мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү һәм территориясе чикләрен раслау турында» 2021 елның 17 февралендәге 33-П номерлы боерыгына 1 кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).

2. Әлеге боерыкка 2 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында урнашкан «Урта Куланга җирлеге» археологик мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү һәм территориясе чикләрен раслау турында» 2021 елның 17 февралендәге 33-П номерлы боерыгына 2 кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).

3. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының «Татарстан Республикасының Кайбыч муниципаль районында урнашкан «Урта Куланга җирлеге» археологик мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү һәм территориясе чикләрен раслау турында» 2021 елның 17 февралендәге 33-П номерлы боерыгын Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында урнашкан «Урта Коланга җирлеге» археологик мирас объекты территориясеннән файдалану режимын раслау турында 3 нче кушымта белән тулыландырырга.

4. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Комитет рәисе урынбасары М.М. Вәлиуллинга йөкләргә.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2021 елның 17 февралендәге 33-П боергына 3 кушымта
(Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының «__»_______2021 №___боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасының Кайбыч муниципаль районында урнашкан «Урта Куланга җирлеге» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән файдалану режимы

Чикләрендә ачыкланган археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым режимы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 73-ФЗ номерлы Федераль закон), җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре, ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, шулай ук гражданнарның күрсәтелгән объектка керүен тәэмин итү шартларында урманнардан һәм башка эшләрдән файдалану буенча эшләр башкару мөмкинлеген күздә тота.